**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4010**
**09.08.2022**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 12 июлендәге 4692 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 пунктның 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 12 июлендәге 4692 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| 5. | 3D модельләштерүдә һәм прототиплаштыруда ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |

2) түбәндәге эчтәлектәге 9-12 пунктлар өстәргә:

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| 9. | Башлангыч робот техникасында ТРИЗ | кеше/ай | 2000,00 |
| 10. | Проект эшчәнлегендә ТРИЗ | кеше/ай | 2000,00 |
| 11. | Алгоритмика | кеше/ай | 500,00 |
| 12. | Кул белән | кеше/ай | 500,00 |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов